Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең
Васильевка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

01 ноябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 01 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлеге Васильевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су насосы сатып алу); традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору, (агачлар һәм куакларны кисү); тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (тукталыш павильоны сатып алу)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 250 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 196 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 186 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 10 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Васильевка авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Василҗевка авыл җирлеге Васильевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су насосы сатып алу); традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау,

коймалар кору, (агачлар һәм куакларны кисү); тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (тукталыш павильоны сатып алу)» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныруга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Васильевка авылы, Үзәк урам, 26 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Васильевка авыл җирлеге башлыгы Ш.М. Касыймуллин